СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» Сабакайка авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25.10.2025 г. № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясына туры китереп 2025 елның 25 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2026 елда Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Сабакайка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан, 18 яшькә кадәрге 3 баласы булган гаиләләрдән тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, үзагымлы изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контактторлар сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 65 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 53 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 50 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 3 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Сабакайка авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2026 елда Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Сабакайка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан, 18 яшькә кадәрге 3 баласы булган гаиләләрдән тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, үзагымлы изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контактторлар сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Сабакайка авылы мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районының «Алексеевск**
**шәһәр җирлеге» муниципаль**
**берәмлеге Башлыгы** **С.А. Демидов**